МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ЛИЦЕЙ-ИНТЕРНАТ ИМЕНИ МУСТАФЫ ОНДЖЕЛЯ БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Подписано цифровой подписью: МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ЛИЦЕЙ-ИНТЕРНАТ ИМЕНИ МУСТАФЫ ОНДЖЕЛЯ БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Дата: 2025.03.03 14:31:08 +03'00'

Министерство образования и науки Республики Татарстан
УО исполнительного комитета Бугульминского муниципального района
МБОУ лицей-интернат имени Мустафы Онджеля

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДАЮ |
|---|---|---|
| Руководитель МО учителей Родного( тат.) | ЗДВР МБОУ лицея-интерната имени М.Онджеля БМР РТ | Директор МБО лицея-интерната имени М.Онджеля БМР РТ |
| _______Зайнуллина Р.С. | _______Чинар Г.Д. | _________Сабиров А..И. |
| Протокол №1 от 26.08.24 | | Приказ №1от 29.08.24 |

# Рабочая программа дополнительного образования по социально-гуманитарному направлению театра « Мирас »

На 2024-2025 учебный год

Доган Д.И.
педагога – дополнительного образования
МБОУ лицея-интерната имени Мустафы Онджеля
Бугульминского муниципального района
Республики Татарстан

Рассмотрено на заседании
Педагогического совета
Протокол №1 от 26.08.2024

Бугульма, 2024у.г.

# “Кызыклы татар теле” ТҮГӘРӘГЕНЕҢ

## ЭШ ПРОГРАММАСЫ

| | |
|---|---|
| **Белем бирү баскычы** | Төп гомуми белеем бирү |
| **Сыйныф** | 6 |
| **Эш программасын үзләштерү аралыгы** | 1 ел |
| **Үзләштерү дәрәҗәсе (база, профиль)** | база |
| **Төзүче** | Доган Д.И. |

Педагогик киңәшмә

утырышында кабул ителде

беркетмә № 1

26» нчы август, 2024 нче ел

**Аңлатма язуы**

“Күңелле татар теле” түгәрәге программасы 5-6 сыйныфларда укучы балаларга татар телен тирәнтен өйрәнү өчен төзелгән. Әлеге программа 1 сәгатькә исәпләнгән. Ул атнага 1 тапкыр үткәрелә һәм 45 минут дәвам итә. Программа берничә теманы үз эченә ала. Аларның һәркайсында төрле эш формалары һәм ысуллары: лекция, семинар, әңгәмә, укучыларның мөстәкыйль, гамәли һәм иҗади эшләр кулланыла.

Программада тәкъдим ителгән темалар укучылар өчен кызыклы, аларны иҗади эзләнергә, фикер йөртергә өйрәтә, мәктәп программасының дәвамы була ала.

***Түгәрәк программасының максаты:***

Татар һәм рус тел белемен өйрәнүгә зур өлеш керткән галимнәрнең эшчәнлеге турында кыскача мәгълүмат бирү. Дәрестә алаган белемнәрне тирәнәйтү һәм киңәйтү, аларны тормышта гамәли куллана белү күнекмәләрен бирү.

Укучыларга татар һәм рус телләренең кайбер темаларын чагыштырып өйрәтү. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү, татар халык авыз иҗаты белән таныштыру, аларны өйрәнүдә милли төбәк компоненты куллану.

Дәүләт теле буларак татар теленең аралашу даирәсен киңәйтү, аның дәрәҗәсен күтәрү, телгә мөнәсәбәттә ихтирам тәрбияләү. Укучыларда җаваплылык хисе тәрбияләү, бер-береңә игътибарлы булуны, ярдәм итүне үзмаксат итеп кую.

***Программаның бурычлары:***

Татар һәм рус телләре грамматикасының кайбер темаларын чагыштырып өйрәнүдә укучыларның интеллектуаль һәм гамәли белем-күнекмәләрен үстерү өчен шартлар тудыру.

Татар һәм рус телләрендә охшашлыкны һәм аермалыкны өйрәтү.

***Курсның программасы:***

- ✓ укучыларның татар телен өйрәнүгә карата иҗади активлыкларын арттыру;
- ✓ сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның киләсе үсешенә булышлык күрсәтү;
- ✓ курс турында кыскача мәгълүмат бирү;
- ✓ дәрестә алган грамматик, орфографик, пунктуация, сөйләм теле һәм язу күнекмәләрен ныгыту һәм үстерү;
- ✓ иҗат эше белән шөгыльләнү һәм материалларны төрле басмаларга тәкъдим итү;
- ✓ төрле темаларага проектлар эшләү;
- ✓ район, республика күләмендә үткәрелә торган бәйгеләрдә катнашу;
- ✓ еллык эшкә йомгак ясау.

**Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр:**

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү:
- милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;
- күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз алдыңа максат кую, аңа ирешү юлларын эзләү;
- уңышларыңа яки уңышсызлыкларыңа, аларның сәбәпләренә дөрес бәя бирү;
- индивидуаль эшчәнлек стилен формалаштыру:
- төрле мәгълүмат чараларын (сүзлекләр, Интернет ресурслар һ.б.) танып-белү һәм аралашу вакытында куллану;
- активлыкка, мөстәкыйль, иҗади фикер йөртергә, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген башкару, шәхес буларак формалашуны дәвам итү;
- үзең алган белем күнекмәләрен тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

**Танып-белү гамәлләре:**

- танып-белү юнәлешендәге максатларны билгеләү;
- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра
- белүе, бәяләве, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;
- мөстәкыйль рәвештә теманы, куелган проблеманы ача белү, фикер йөртү;

- уку мәсьәләсе тирәсендә логик фикерләү;
- фикерләүдә логик чылбыр төзү;
- тема тирәсендәге төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;

**Коммуникатив УУГ:**

- тыңлый белү;
- диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;
- сыйныфташлары һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;
- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
- үз фикерен дәлилли белү, тормыштан мисаллар китерү;
- төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
- үз фикерен тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;
- күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;
- мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек итүдә инициативасы күрсәтү;
- укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;
- башкаларны тыңлый, киңәш бирә белү;
- сыйныфташлары каршында төрле темаларга, башкарылган проектлар буенча чыгыш ясау;
- иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү, күршең белән хезмәттәшлек итү.

**Регулятив УУГ:**

- проблеманы аңлап гипотеза чыгару, үз фикереңне дәлилләр китереп раслый белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;
- максатка ирешү юлларын билгеләү;
- үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәле булуына ирешү, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу;
- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү;
- кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу;
- эшләнгән эшкә бәя бирү, сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

**Предмет нәтиҗәләр:**

- исем, фигыль, зат алмашлыкларын табарга өйрәтү, аларның морфологик үзенчәлекләрен һәм җөмләдә кулланылышын аңлау;
- сүз төркемнәрен дөрес язу, аларны сөйләмдә дөрес куллана белү күнекмәләрен үстерү;
- сүзтезмәләрне аера белү, алардагы ияртүче һәм ияручe сүзне билгеләп, бәйләүче чараларны күрсәтү;
- морфологик, синтаксик анализ ясау элементларын үзләштерү;

- телдән һәм язма сөйләмне синонимнар, фразеологизмнар белән баету, бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләрдән дөрес файдалана белү, сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен урынлы куллану;
- төрле телләрдән кергән сүзләрнең мәгънәләрен аңлап куллану һәм дөрес әйтү күнекмәләре булдыру;
- сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыруны дәвам итү;
- телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү;
- укучыларны иҗади эшчәнлеккә тарту, проект эшләре белән кызыксындыру.

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- укучыда укуга, ана теленә карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- кабатлау процессында ана теленең әһәмиятен аңлау;
- иҗади фикерләү өчен шартлар тудыру. Дөрес сөйләм булдыруга омтылыш. Туган телдә аралашу өчен кирәк булган сүзлек составын белү;
- укучыларда грамоталы булу теләген уяту;
- грамоталы булуның өстенлекле якларын күрергә өйрәнү;
- тел байлыгын, грамоталылыкны арттыру өстендә эшләүне булдыру. Иптәшләрнең фикеренә, эшчәнлегенә уңай мөнәсәбәт булдыру;
- сүз байлыгын, әһәмиятен аңлы куллану күнекмәсе булдыру.

## ПРОГРАММАНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

| **Эчтәлек** | **Оештыру формасы** | **Эшчәнлек төре** |
|---|---|---|
| 1.Кереш (1 сәг).<br>Түгәрәк эшчәнлеге белән танышу, әңгәмә үткәрү, монолог/диалог төзү кагыйдәләре белән танышу. | Әңгәмә | Проблемалы укыту<br>Танып-белү/уен эшчәнлеге |
| 2. Татар һәм рус телләрен чагыштыру (2 сәг).<br>Күренекле рус һәм татар тел галимнәре, тел белгечләре турында мәгълүмат алу, татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәнүнең кыскача тарихына күз салу. | Лекция<br>Әңгәмә | Проблемалы укыту<br>Чагыштырып өйрәнү<br>Танып-белү эшчәнлеге |
| 3. Фонетика (2 сәг).<br>Интонация һәм аның сөйләмдәге роле, фонетика курсы, фонетик транскрипция, шарадалар, | Әңгәмә<br>Түгәрәк өстәл | Проблемалы укыту<br>Танып-белү/уен эшчәнлеге |

| | | |
|---|---|---|
| кроссвордлар чишү. | Уен | |
| 4. Графика (4 сәг).<br>Язу ничек барлыкка килгән? Алфавитны искә төшерү, дөрес әйтелеш кагыйдәләрен барлау. | Рольле уен<br>Лекция<br>Әңгәмә | Танып-белү/уен эшчәнлеге |
| 5. Лексика (4 сәг).<br>Синонимнар, антонимнар, омонимнар, мавыктыргыч фразеологизмнар, күпмәгънәле сүзләр иленә сәяхәт кылу. Викторина «Сүзләр илендә» үткәрү. Конкурска әзерләнү. | Лекция<br>Әңгәмә<br>Рольле/төркемле уен | Танып-белү/уен эшчәнлеге<br>Күңел ачу эшчәнлеге |
| 6. Синтаксис (5 сәг).<br>Сүзтезмә, җөмлә кисәкләре, җөмләдә сүзләр тәртибе, рус теленнәе татар теленә, татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләре белән танышу. | Лекция<br>Әңгәмә<br>Түгәрәк өстәл<br>Уен | Танып-белү/уен эшчәнлеге<br>Күңел ачу эшчәнлеге |
| 7. Әдәби дөнья (5 сәг).<br>Тел турында мәкальләр һәм әйтемнәр, татар халык авыз иҗаты, әкиятләр, табышмаклар, әкият язу | Әңгәмә<br>Түгәрәк өстәл<br>Уен | Проблемалы укыту эшчәнлеге<br>Танып-белү/уен эшчәнлеге<br>Күңел ачу эшчәнлеге |
| 8. Туган телеңне белү кирәк (1 сәг).<br>Тел дигән дәрья бар... Сирәк очрый торган Аурупа телләре, без яшибез татар илендә, сөйләшәбез татар телендә, урамнарда йөрдем хата эзләп... | Әңгәмә<br>Түгәрәк өстәл | Проблемалы укыту эшчәнлеге<br>Танып-белү/уен эшчәнлеге<br>Күңел ачу эшчәнлеге<br>Туристлык эшчәнлеге |
| 9. Милли йола (3 сәг).<br>Татар халкының милли йолалары, бәйрәмнәре, аш-сулары. | Әңгәмә<br>Уен<br>Бәйге | Проблемалы укыту эшчәнлеге<br>Танып-белү/уен эшчәнлеге<br>Күңел ачу эшчәнлеге |
| 10. Исемнәр тарихы (2 сәг).<br>Аны болай язалар... (тәрҗемәи хәл язырга өйрәтү), исемнәр тарихы, борынгы һәм хәзерге исемнәр, синең исемең нәрсә аңлата? | Лекция<br>Әңгәмә<br>Уен | Проблемалы укыту эшчәнлеге<br>Танып-белү/уен эшчәнлеге<br>Күңел ачу эшчәнлеге |

| | | |
|---|---|---|
| 11. Проект эше әзерләү (2 сәг).<br>Нәрсә ул проект? Аны ничек әзерләргә? Проект эше әзерләү, яклау. | Лекция<br><br>Әңгәмә | Проблемалы укыту эшчәнлеге<br>Танып-белү/уен эшчәнлеге<br>Проект эшчәнлеге |
| 12. И туган як (2 сәг).<br>Тапкырлар һәм зирәкләр бәйгесе, туган ягым – Татарстан, тылсымлы сүзләр, “И туган тел...” | Бәйге<br><br>Кичә | Проблемалы укыту эшчәнлеге<br>Танып-белү/уен эшчәнлеге<br>Кичә |
| Гомуми (34 сәг) | | |

**ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ**

| № | Тема | Сәгатьсаны | Оештыру формасы |
|---|---|---|---|
| 1 | Кереш. Түгәрәк курсының эчтәлеге белән танышу. | 1 | Әңгәмә |
| 2 | Күренекле рус һәм татар тел галимнәре, тел белгечләре турында мәгълүмат. | 1 | Лекция |
| 3 | Татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәнүнең кыскача тарихы. | 1 | Лекция |
| 4 | Интонация һәм аның сөйләмдәге роле. | 1 | Әңгәмә |
| 5 | Фонетика патшалыгына сәяхәт. | 1 | Түгәрәк өстәл |
| 6 | Фонетик транскрипция. | 1 | Мөстәкыйль эш |
| 7 | Шарадалар һәм метаграммалар. | 1 | Уен |
| 8 | Графика. Язу ничек барлыкка килгән? | 1 | Лекция |
| 9 | Алфавитта кемнәр яши? | 1 | Рольле уен |
| 10 | Лексика. Синонимнар, антонимнар, омонимнар. | 1 | Лекция |
| 11 | Мавыктыргыч фразеологизмнар. | 1 | Уен |
| 12 | Күпмәгънәле сүзләр. | 1 | Түгәрәк өстәл |
| 13 | Викторина «Сүзләр илендә». | 1 | Төркемле уен |
| 14 | Синквейн төзү | 1 | Түгәрәк өстәл |
| 15 | Сүзтезмә | 1 | Әңгәмә |
| 16 | Җөмлә кисәкләре. | 1 | Лекция, мөстәкыйль эш |
| 17 | Җөмләдә сүзләр тәртибе. | 1 | Төркемле уен |
| 18 | Татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләре. | 1 | “Тәрҗемәче” уены |
| 19 | Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләре. | 1 | “Тәрҗемәче” уены |
| 20 | Тел турында мәкальләр һәм әйтемнәр. | 1 | Белем аукционы |
| 21 | Татар халык авыз иҗаты. Әкиятләр. | 1 | Әңгәмә |
| 22 | Табышмаклар. | 1 | “Кем тизрәк” уены |
| 23 | Үзебез әкият язабыз. “Сабантуй”, “Көмеш кыңгырау” газеталарына, “Ялкын” журналына тәкъдим итү. | 1 | Проект |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 24 | Олимпиадага әзерлек | 1 | Лекция, әңгәмә |
| 25 | Тел дигән дәрья бар...<br>Сирәк очрый торган Аурупа телләре. | 1 | Аурупага читтән торып экскурсия |
| 26 | Без яшибез татар илендә, сөйләшәбез татар телендә. | 1 | Кичә |
| 27 | Урамнарда йөрдем хата эзләп... | 1 | Шәһәр урамнарына экскурсия |
| 28 | Татар халкының милли бәйрәмнәре. | 1 | Уен |
| 29 | Аны болай язалар... (тәрҗемәи хәл язырга өйрәтү). | 1 | Лекция |
| 30 | **Исемнәр тарихы.**<br>Борынгы һәм хәзерге исемнәр.<br>Синең исемең нәрсә аңлата? | 1 | Лекция<br><br>Әңгәмә |
| 31 | Нәрсә ул проект? Аны ничек әзерләргә? | 1 | Лекция |
| 32 | Проект эше әзерләү. | 1 | Проект |
| 33 | Проект яклау. | 1 | Проект |
| 34 | “И туган тел...” (әдәби кичә) | 1 | Әдәби кичә |